

# ШАИДА МАКСУДОВА

(1926-2009)

Переводчик, писательница, член Союза писателей РТ.

Шаида Максудова родилась 29 ноября 1926 г. в д. Уразаево Агрызского районав семье муллы.

Публиковала свои произведения под псевдонимом Гульшахида. На её литературном счету несколько повестей, рассказы, литературоведческие и критические статьи, стихи, а также многочисленные переводы на татарский язык с русского, башкирского, каракалпакского и других языков. Книги переводов Шаиды Максудовой в своё время выходили в Казани, Москве, Уфе, Алма-Ате…

Много лет она заведовала библиотекой Союза писателей, работала в Книжной палате РТ, различных редакциях в Казани и Альметьевске, в годы войны учительствовала, закончила татарское отделение истфилфака КГУ, где и познакомилась со своим будущим мужем (они учились в одной группе) — начинающим писателем, студентом Гарифом Ахуновым, которому на долгие годы стала первым читателем и критиком, они прожили дружно и творчески вместе полвека… Многие отмечали, что родительский дом отличался гостеприимством, уютом и хлебосольством, мама прекрасно готовила, любила печь пироги, эчпочмаки, балиш, перемячи, готовитьваренья-соленья, пастилу из калины и яблок… Родители часто пели дуэтом, читали вслух друг другу, обсуждали книжные новинки, часто ходили вместе в театр, в гости, на концерты татарской музыки. Они были очень дружными, сильно скучали в моменты разлуки. А в свой последний юбилей папа усадил маму рядом с собой на сцене Камаловского театра и, кажется, так его примеру никто и не решился позже последовать…

Прозу и поэзию Гульшахиды, как отмечают многие, отличают естественность интонации, тонкий лиризм, мягкий юмор. На некоторые стихи написаны песни. Её книга прозы «Минем кала алуым» (Казань, Таткнигоиздат, 2006), изданная к 80-летию, очень скоро исчезла с книжных прилавков и стала библиографической редкостью. А повесть «Я и город белокаменный» в пер. Р. Ахунова вошла в сборник лучших произведений татарских писателей для юношества «На Волге, на Идели», изданный в Москве в 1983 году.

Язучы, тәрҗемәче Шәһидә Габдерахман кызы Максудова-Ахунова (әдәби тәхәллүсе — Гөлшәһидә) 1926 елның 29 ноябрендә Татарстанның Әгерҗе районы Уразай авылында мулла гаиләсендә туа.

Шәһидә әүвәл авыл мәктәбендә укып, 1939-1942 елларда укуын Казанның татар һәм рус мәктәпләрендә дәвам иттерә. Сугыш башлангач, укуын бүлеп, 1942-1946 елларда Татарстанның Красный Бор районы Салагыш җидееллык мәктәбендә укытучы булып эшли. 1946 елда янәдән Казанга әйләнеп кайтып, 80 нче татар кыз балалар мәктәбендә урта белем алгач, шул ук елны (1947) Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1952 елда университетны тәмамлагач, берникадәр вакыт «Пионер» (хәзерге «Ялкын») журналында хатлар бүлеге мөдире, 1954-1957 елларда ТАССР дәүләт китап палатасында библиограф, 1958-1968 елларда әүвәл Әлмәт төбәк газетасы «Хезмәт байрагы» редакциясендә әдәби хезмәткәр, аннары сигез елга якын Әлмәт фәнни-техник әдәбият китапханәсендә өлкән библиограф булып эшли. 1969-1983 елларда Шәһидә Максудова Татарстан Язучылар берлеге китапханәсенең мөдире сыйфатында хезмәт эшчәнлеген дәвам иттерә. Ш.Максудова, иҗади шәхес буларак, укучылар даирәсенә проза жанрында язылган берничә оригинал әсәре һәм тәрҗемә китаплары белән мәгълүм. Ул — бигрәк тә тәрҗемә өлкәсендә активлык күрсәткән каләм иясе. Аның тәрҗемәсендә татар укучылары Л.Толстойның хайваннар турындагы хикәяләре, совет чоры рус язучыларыннан А.Грин, А.Батров, С.Антонов, В.Чивилихин әсәрләре, молдован, казакъ, каракалпак прозаиклары иҗатыннан аерым үрнәкләр белән таныштылар. Тәрҗемәләренең бер өлеше аерым китаплар рәвешендә нәшер ителеп, икенче бер өлеше «Ак дөя» (1979), «Зирәк кеше» (1980), «Арал дулкыннары» (1981), «Дуслык аланы» (1987) кебек күмәк җыентыкларда урын ала.

Ш. Максудованың оригинал әдәби иҗатыннан үз биографиясенә бәйле тормыш материалына һәм шәхси кичерешләренә нигезләнеп язылган «Минем кала алуым» исемле кечкенә повесте (1972) укучылар арасында аеруча җылы каршы алына. Әсәр, Рәшит Ахунов тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, «Я и город белокаменный» исеме белән «Волга» журналында (Саратов, 1972, № 2), «Между Волгой и Уралом» (Йошкар-Ола, 1978), «На Волге, на Идели» (Мәскәү, «Детская литература» нәшрияты, 1983) исемле күмәк җыентыкларда кат-кат нәшер ителә, 1979 елда Сара Латиева тәрҗемәсендә казакъ телендә дә басылып чыга. 1997 елда «Казан утлары» журналының 11 нче санында дөнья күргән һәм гаилә эчендәге мөнәсәбәтләрне нечкә психологик алымнар белән реалистик планда ышандырырлык итеп сурәтләгән «Асылбикәне җирләгәндә» повесте да әдәби тәнкыйтьтә авторның иҗади уңышы итеп бәяләнә. Ул 2009 елның 8 февралендә Казанда вафат була.

Ш.Максудова — 1992 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## ТӨП БАСМА КИТАБЫ

Минем кала алуым: повестьлар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 63 б. — 1000 д.
Толстой Л. Булька: хайваннар турында хикәяләр. — Казан: Татгосиздат, 1953. — 28 б. — 10000 д.
Б а т р о в А. Дустыбыз Хосе: хикәяләр. — Казан: Таткнигоиздат, 1954. — 1106. — 10000 д. Коллектив. Дөньяда ниләр бар? / К.Шәфыйкова белән уртак тәрж. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. — 390 б. — 10000 д.
Антонов С. Аленка: хикәяләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. — 232 б. — 10000 д.
Чивилихин В.Урман-чытырман:повесть. — Казан:Татар.кит.нәшр., 1977. — 1846. —15000 д.

## ИҖАТЫ ТУРЫНДА

Низамиев Р. Тынгысыз сабырлык // Казан утлары. — 1996. — № 11. — 123-124 б.
Мулланурова Р. Якты сагыш // Сөембикә. — 1996. — №11. — 196.
Рәшит Ә. Уеңны уйдырып салсаң... // Шәһри Казан. — 1998. — 16 гыйнв.

---

Әдипләребез. Биобиблиографик белешмәлек. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2009




Молодожены: Гариф Ахунов и Шаида Максудова (Ахунова),
Шаида Максудова (Ахунова) с дочерью1960 г. Наилей